Алга, белем иленә!

# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче лицей
«Фарватер» укучыларының нәфис басмасы

25 нче ноябрь, 2017 ел
№ 1

## Әлеге санда

Безгә һәрчак Сез кирәк
(3 - 4 нче битләр)

Нинди түгәрәк сайларга?
(5 нче бит)

Әни дигән газиз сүз
(6 - 8 нче битләр)

Хисләрем сыймый күңелгә
(9-10 нчы битләр)

Бәйгедә катнаш һәм бүләк от!
(10 нчы бит)



## «ТАТАР КЫЗЫ, ТАТАР ЕГЕТЕ - 2017»

Татар дөньясын рухландырып, быел да башкалабызда бик күркәм «ТАТАР КЫЗЫ, ТАТАР ЕГЕТЕ - 2017» бәйгесе узды. Безнең лицеебыздан иң булган, иң уңган, иң чибәр кыз һәм егет сайланды.

# «ТАТАР КЫЗЫ, ТАТАР ЕГЕТЕ - 2017»

26нчы октябрь көнне Абдуллина Зәринә һәм Инсафетдинов Эмиль район этабында катнаштылар (җитәкчеләре: М.З.Хәмидуллина, Л.Р.Абдуллина, М.Т.Инсафетдинова, Е.А.Корочкина, З.Ю.Вакилова). Әлеге чарада барлыгы 12 пар катнашты. Укучыларыбыз үзләрен өч этапта сынап карадылар һәм дәрәҗәле өченче урынга лаек булдылар. Җиңүчеләрне ихлас күңелдән тәбрик итәбез! Киләчәктә дә иҗади уңышлар телибез!



**Тулы исеме:** Абдуллина Зәринә Рафаэль кызы.

**Тормыш девизы:** “Беркайчан да бирешмәскә!”

**Яраткан җырчысы:** Гүзәл Уразова, Ольга Кормухина.

**Көтеп алган бәйрәме:** Яңа ел.

**Балачак хыялы:** танылган җырчы булу.



**Тулы исеме:** Инсафетдинов Эмиль Наил улы.

**Тормыш девизы:** “Сәламәт яшәү!”

**Яраткан җырчысы:** Салават Фәтхетдинов, Александр Градский.

**Көтеп алган бәйрәме:** Әниләр көне, Сабантуй.

**Балачак хыялы:** бөтендөнья илләренә сәяхәт итү.

# БЕЗГӘҺӘРЧАК СЕЗ КИРӘК



Укытучы – үзенчәлекле һөнәр иясе. Ул кешедән төпле белем, түземлелек, һәр бала белән дустанә мөнәсәбәт сорый.

Укытучылар көне – белем бирү өлкәсендә эшләүчеләрнең һөнәри бәйрәме. Әлеге бәйрәм төрле илләрдә төрле көннәрдә үтә.

Укытучылар көнен без 5 нче октябрьдә бәйрәм итәбез. Бу бәйрәм Россиядә 1965 нче елдан башлап билгеләнә. Россиядә Укытучылар көнен Юнеско бары тик 1994 нче елның 3 нче октябрендә генә Россия Федерациясе президенты карары нигезендә раслады.

Тәүге тапкыр Укытучылар көне Сан-Паулу шәһәрендәге кечкенә генә 1520 нче номерлы мәктәптә, 1947 нче елда үтә.

Әлеге бәйрәм безнең лицеебызда тантаналы рәвештә билгеләп үтелә. Ул көнне уку йортыбызда аеруча күңелле була. Быел да, гадәттәгечә, дәресләрдән соң укытучыларга багышланган зур концерт үткәрелде.

Лицеебыз директоры – Урманчеева Әлфия Госман кызы ел дәвамында ирешкән уңышлары өчен укытучыларны грамота һәм дипломнар белән бүләкләде.

Махсус кунакларыбыз – ветеран укытучыларыбыз бәйрәмебезгә тагын да ямьлерәк төс өстәде.

Укучыларның тырышып әзерләнгән чыгышлары укытучыларның күңелендә җылы эз калдырды.

Хөрмәтле укытучыларыбызны тагын бер кат Укытучылар көне белән тәбрик итәбез! Сезгә шушы авыр, әмма мактаулы эшегездә тазалык, тынычлык, сабырлык, гаилә бәхете телибез. Һәрвакыт шулай сабыр, олы йөрәкле, чибәр булып калыгыз. Без сезнең белән горурланабыз һәм сезнең каршыгызда баш иябез.

*Маслов Олег, 9 е-м*

Сүнгән чакта өметебез,
Калмаган чакта терәк.
Күз яшьләрен сөртә-сөртә,
Юатырга сез кирәк.

Боекмас өчен күңелләр,
Кимсенмәс өчен йөрәк –
Сез кирәк, укытучылар,
Безгә һәрчак сез кирәк!
(Ф. Яруллин)

## Укытучы апа




Укытучы бик ашыга,
Ул бизәнә, киенә.
Мәктәп ишеген ачуга,
Ул үзенчә куана.

Сыйныф бүлмәсен ачуга,
Укучылар елмая.
Алардан да көчлерәк
Апа үзе сөенә.

Укытучы апа диеп,
Ашкына һәрбер бала.
Белемле булсыннар диеп,
Тырыша безнең апа.

*Леонтьева Аделя, 8 м*

## «Иң кадерле кеше» күргәзмәсеннән



# НИНДИ ТҮГӘРӘК САЙЛАРГА?

Лицей укучыларыбыз берсеннән-берсе кызыклырак түгәрәкләргә йөриләр. Безнең укучыларыбыз нинди түгәрәкләрне үз итә? Шул турыда берничә сүз.

Мин хореография түгәрәгенә 5 яшьтән бирле йөрим. Хореографиясез тормышымны күз алдыма да китерә алмыйм. Укытучыларым миңа музыканы ишетергә өйрәттеләр. Ритм төшенчәсе белән таныштырдылар.





Мин футбол түгәрәгенә йөрим. Футбол сәламәтлек өчен, сөякләр, мускулларга файдалы. Кечкенәдән футбол белән шөгыльләнү эшемне алдан планлаштырырга өйрәтте.

Мин күп еллар буе хоккей белән шөгыльләнәм. Хоккей белән шөгыльләнү лидерлык сыйфатын, үзеңне коллективта тота белү, командаң өчен җаваплылык хисен тәрбияли.





Тхэквондога түзем, физик яктан көчле малайларны гына алалар. Шуңа күрә, мин һәркөн иртән физик күнегүләр ясыйм. Башкаларга да сәламәтлекне сакларга киңәш итәм.



# ӘНИ дигән газиз сүз

Әниләр көне безнең илдә 1998 нче елдан башлап бәйрәм ителә. Әлеге бәйрәм быел 26 ноябрьгә туры килә. Һәр кешенең тормышы әниләрнең назыннан, бишек җырыннан һәм кайгыртуыннан башлана. Әйтү өчен гаҗәеп назлы, мәгънәле, ягымлы “әни” сүзе кешенең бөтен гомерен үз эченә ала. Һәркем гомере буе әнисенең якты хатирәсе белән яши, аның куллары һәм йөрәге җылысын тоя, сөйкемле елмаюын хәтерендә саклый.

Җирдә тормышны саклаучылар булган әниләр тирән ихтирам белән баш июгә, мәңгелек мәхәббәткә һәм иң олы хөрмәткә лаеклы. Кадерле аналар! Изге бәйрәм уңаеннан иң җылы һәм ихлас котлауларыбызны кабул итегез. Барлык әниләргә, әбиләребезгә, апа-сеңелләргә ныклы сәламәтлек, озын гомер, бәхет телибез. Гаилә учагыгыз сүрелмәсен, балаларыгызның бәхетен, игелеген күреп, сәламәт

*Нуждина Влада, 9 е-м*

## Әни сүзе

Әнием мине ярата,
Иркәли, сөя.
“Матурым, аппагым минем,
Йолдызым!” – дия.

“Хәерле иртә, кызым!” – дип,
Сыйпап уята.
Иртәнге ашлары белән
Мәктәпкә озата.

“Кызым, яхшы укы!” – диеп
Гел әйтеп тора.
Көндәлектә “биш”ле күрсә,
Күңеле тула.

“Тәртипле бул, һәрвакытта!” –
Бу әни сүзе.
Авыр чаклары булса да
Сиздерми үзе.

*Загриева Фәридә, 3 г*

## ИҢ КАДЕРЛЕ КЕШЕМ — ӘНИЕМ



Син, әнием, минем өчен
Бу дөньяда бер генә.
Елмайганда йөзләреңнән
Бар өйгә нур бөркелә.

Әнкәй, әни, нәнә, инәй... Никадәр мәгънә ята бу сүзләрдә! Һәркемгә үз әнисе бик кадерле булган кебек, миңа да үз әнием – иң кадерле кеше. Безнең телебез “әни” сүзе белән ачылган. Әни – безгә тормыш биргән кеше. Күкрәк сөтен имезеп үстергән, төннәрен, безнең өчен борчылып, бер генә мизгелгә дә керфек какмаган Әниләр.

Иртән йокыдан мине үзенең ягымлы тавышы белән “кызым” диеп сөеп уятуын бик яратам. Тәмле ризыклар пешереп, татлы чәйләр ясагач, мине өстәл янына чакырасың. Хәерле юл теләп мәктәпкә озатасың. Мин авырган вакытта да гел янәшәмдә буласың, кайгыртып торасың. Үзеңнең җылы кулларың белән мине сыйпап алсаң да, авыруым бетеп киткәндәй була. Әни әле минем иң якын сердәшчем, аңа серләремне сөйләсәм рәхәт булып китә. Ул һәрвакыт миңа булышып, акыллы киңәшләрен биреп тора. Әниләр синең шатлыгыңны да, кайгыңны да, уйларыңны да бик тиз сизеп ала. Әнинең сүзен тыңларга тырышам, алар бит һәрвакыт дөрес әйтәләр. Борчылган чагымда, әниемнең чын йөрәктән чыккан сүзләрен тыңлагач, минем борчуларым һәм проблемаларым онытыла. Тынычландыручы да, кичерүче дә, бәхетле итүче дә син, әни.

*Семёнова Снежана, 8 м*



## ӘНИЕМНЕН ҖЫЛЫ КОЧАГЫ

Әни! Нинди тирән мәгънәгә ия бу сүз. Бу сүзне телгә алу белән, һәр кеше үзенең балачагын бер кат күздән кичерәдер, минемчә.

Мин тормышымны әниемнән башка күз алдына китерә алмыйм. Хәлемнән килсә, бер генә минутка да әниемнән аерылмас идем.

Балалар бакчасына йөргәндә дә, әниемнең итәгенә ябышып, озак кына елап калган көннәрем бүгенгедәй хәтеремдә.

Безгә әниләр якын булган кебек, әниләребезгә дә без бик кадерле. Алар безнең өчен борчылып, киләчәгебезне кайгыртып яшиләр. Тамагыбыз тук, өстебез бөтен булсын диеп тырыша. Әнием пешергән кайнар ризык исләре гел борынымны кетекләп торадыр кебек.

*Гыйлметдинова Лилия*

## Әни мәхәббәте

Минем өчен әнием
Иң кадерле кешем.
Әниемне сөендерсен
Минем һәрбер эшем.

Әкиятләр, җырлар белән
Йокыга озата.
Әллә минем әни генә
Шулай ярата?

*Вәлиев Наил,*

## Буй җитмәс биеклек

“Мин галәмне гиздем, космонавт булдым, аяк басмаган илем юк, дус-ишләрем дә бихисап. Үзем дә әни булдым, кызыма әниемнең исемен куштым. Шулай да минем өчен кадерле әнием һаман да буй җитмәс биеклек, тиңдәшсез акыл иясе булып кала.”

*Валентина Терешкова*

## Сер сандыгы

“Дөньяда вакытта шатлыкларны һәм кайгыларны уртаклашыр өчен якын һәм ышанычлы кешеләр кирәк була. Балалар өчен əти-әнисеннән дә ышанычлырак кеше һич булмас. Алар баланың шатлыгы өчен үзеннән дә артыграк сөенәләр, ә кайгы-хәсрәтләрен җиңеләйтү өчен кулларыннан килгән чараларның бөтенесен эшләргә тырышалар. Шуның өчен серләрегезне аларга гына сөйләгез, серләрегез хәзинәләре һәрвакыт ата-аналарыгыз күңелендә булсын”.

*Риза Фәхреддин*

## УЙЛАНЫРГА ВАКЫТ

Моннан инде дистә елга якын...
Алам белем, табам хәзинә.
Кем булырга? дигән сорау туа.
Нәтиҗәләр ясыйм үземә.

Укытасым килә татар телен,
Матур әдәбият битләрен,
Туган телем минем, иркә гөлем,
Бай мираслы шиъри көйләрен.

Әллә, димен, мин дә халкым өчен
Кертсәм әгәр бер зур өлешем.
Туплап белем, милли үзаң көчен
Туган телгә алтын-көмешем.

Укытучы-галим булу теләк.
Шундый минем дөнья карашым:
Фәнебезне үстерергә кирәк,
Сындырмаска аның канатын!

Татар теле укытучысы булам!
Үстерәмен туган телемне!
Тукай көчен китаплардан алам,
Алга алып барам илемне.

Моннан инде дистә елга якын...
Алам белем, табам хәзинә.
Кем буласым хәзер төгәл беләм:
Укытучы булам үзем дә!


*Инсафетдинов Эмиль, 9 е-м*

# Бәйге!

**Кагыйдәләр:**

Рәсемдәге буш урынга кызыклы комментарий уйлап тап һәм җавабыңны 212 нче кабинетка хәбәр ит.

Дуслар, иң кызык комментарий авторын бүләк көтә!



## Укучыларыбыз иҗаты



Морозов Ярослав



Мәрвәрова Камилә


Морозов Ярослав


Гыйлметдинова Лилия


Сәгъдиева Диләрә

Безнең адресыбыз: Казан шәһәре Идел буе районы “78 нче лицей ”Фарватер”

(Ю.Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139 тел./ факс 268-58-61.

E-mail: school_7878@mail.ru

Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин: https://edu.tatar. ru/priv/school78.htm/ page813169. htm

**Мөхәррир:** *Семёнова Снежана,*
*Инсафетдинов Эмиль,*
*Гыйлметдинова Лилия,*
*Маслов Олег.*
***Консультант:*** *Фәйзуллина Рәзилә Яудәт кызы.*